**ГЛАВА**
**Кудашевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.11.2025 Кодаш авылы № 3

Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлегенең Иске Кызылъяр торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

Гамәлдәге законнар нигезендә, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Уставының 14 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге башлыгы карар кабул итә:

1.2025 елның 12 ноябрендә 8 сәгать 30 минутта Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Иске Кызылъяр торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Кызылъяр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (I төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, иреклеләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (бергә яшәүче ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалары) тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 600 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге җирлек өчен әһәмиятле эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?”

1. Җирлек территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, урам юлларын ремонтлау.

2. Иске Кызылъяр авылының су башнясын, суүткәргечен ремонтлау, аңа хезмәт күрсәтү өчен сантехник һәм чыгым материаллары сатып алу (тирән насослар һәм башка материаллар сатып алу)

3. Янгын сүндерү машинасын тоту, ремонтлау, запас частьләр сатып алу.

4. Кышын-язын - кардан, җәйге-көзге чорда үләннән чистарту өчен тракторга дизель ягулыгы һәм запас частьләр сатып алу.

5. Авыл зиратын әйләндереп алган коймаларны төзәтү.

6. Санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Иске Кызылъяр авылында санкцияләнмәгән чүплекне бетерү).

“РИЗА” "КАРШЫ"

3.Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Татарстан Республикасы, Әгерҗе районы, Иске Кызылъяр авылы, 30нчы йорт янында.

4.Кодаш авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче Ф.М. ШАКИРОВ